| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>КУЛАНГИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>КОЛАНГЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

21.11.2025 ел Колаңгы т.юл ст. № 7

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлеге Советының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

Муниципаль норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Колаңгы авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлеге Советының түбәндәге карарлары үз көчләрен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Колаңгы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру, шулай ук «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Колаңгы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмәне раслау турында» 2014 елның 14 октябрендәге 26 номерлы;

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлеге Советының «Кайбыч муниципаль районының Колаңгы авыл җирлеге Советының 2014 елның 14 октябрендәге 26 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Колаңгы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру, шулай ук «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Колаңгы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 декабрендәге 44 номерлы.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) һәм Колаңгы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырырга һәм Татарстан Республикасының Кайбыч муниципаль

районы Колаңгы авыл җирлегенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Совет рәисе,
Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районының
Колаңгы авыл җирлеге Башлыгы Ф.Т.Нигъмәтҗанов